ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
423750, Уразай авылы,
Центральная урамы, 4 нче йорт.
тел.3-44-62
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

УРАЗАЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423750, дер.Уразаево,
ул.Центральная,
дом 4., тел. 3-44-62.
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**17 январь 2020 ел** **№3**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең 2020 елга эш планын раслау турында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 14.10.2011 № 71-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Уразай авыл җирлеге Уставы нигезендә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау, гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатыннан КАРАР БИРӘ:

1. Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссиянең эш планын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми pravo.tatar.ru сайтында, Уразай авыл җирлеге http://aktanysh.tatar.ru/rus/aktanysh/poselenia сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Уразай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Шарипов

Уразай авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесенең
17.01.2020ел №3 карарына
кушымта

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең

2020нче елга эш планы

| № п/п | Мероприятие | Үтәү вакыты | җаваплы | Кем белән берлектә үткәрелә |
|---|---|---|---|---|
| | Оештыру-методик эш | | | |
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы (Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районындагы беркетмәләре һәм күрсәтмәләре буенча балигъ булмаган балаларга һәм аларның ата-аналарына карата материалларны карау, белем бирү учреждениеләре тәкъдимнәре һәм үтенечнамәләре, гражданнарның шикаятьләре, торак шартларын тикшерү актлары һ. б.) | Кварталга 1 тапкыр | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Уразай авыл җирлеге авылларында КБН һәм ЗП күчмә утырышларын үткәрү | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 3. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рейдлары | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында эчкечелекне кисәтү максатыннан яшүсмерләр | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | концентрациясе урыннары (дискотекалар, урамнар) буенча рейдлар | | | |
| 5. | Сәүдә нокталары буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 6. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы КДН һәм ЗП утырышларында чыгарылган штрафлардан качып йөрүче гражданнар буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 7. | Имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм аларны КДН, ЗП һәм ПДНда исәпкә кую | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 8. | Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча яшүсмерләр һәм аларның ата-аналарын кабул итү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 9. | Гаилә көненә, Балаларны яклау көненә, Яңа елга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышында карау өчен чыгарылган мәсәләләр

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларның һәм җинаятьләрнең торышы турында | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Дәресләргә йөрмәгән балалар турында һәм мондый очракларга юл куймау буенча җирлек мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрелгән чаралар һәм балигъ | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составы турында мәгълүмат | | | |
| 3. | Яшәү урыны буенча Балигъ булмаганнарның ялын оештыру турында | Ел дәвамын да | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 4. | Күп балалы һәм имин булмаган гаиләләр белән эшләү | Ел дәвамын да | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 5. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия эшенә йомгак ясау | Ел дәвамын да | Комиссия рәисе | Комиссия составы |